Актаныш районы Чуракай төп гомуми белем бирү мәктәбе

# "Актанышым-туган ягым"

Үткәрде: татар теле һәм әдәбияты укытучысы
Миназова Р.З.

**Максат:** Актанышның,туган авылыбыз Чуракайның үткәне, бүгенгесе белән кызыксыну уяту. Туган якның изгелеген аңлый белү, күренекле шәхесләребез белән горурлану хисе тәрбияләү.
**Җиһаз**: Чуракай авылына нигез салучы Чурагол нәселе шәҗәрәсе, Актаныш картасы, Актаныш гербы, туган як турында плакатларга язылган мәкальләр, магнитофон язмасы: Ә.Авзалова башкаруында "Актаныш таңнары" җыры.
**Үткәрү формасы**: ачык аралашу сәгате.

Дәрес барышы.
1 алып баручы:Укучылар, сезнең телевизордан рекламалар күргәнегез бар. Әллә нинди шоколод, соклар, аяк киемнәре, бизәнү әйберләре, тагы әллә ниләр рекламалыйлар. Аларны карагач, кызыгып куясың. Алып ашыйсың, киеп сөртеп карыйсың килә.Реклама- кызыксындыру дигән сүз ул.Минем дә сездә кызыксыну уятасым килә.
2 алып баручы: Ә менә нәрсәгә кызыксыну уятасыбыз килә икә? Бу сорауга сез түбәндәге шигырьне тыңлагач,җавап бирерсез.

Туган илкәй...
Ни аһәңле, назлы исем!
Сизәм анда болыннарның татлы исен,
Ишетәм анда яфракларның серле шавын,
Тау астында салкын чишмә чылтыравын,
Саклыйм аңа чын мәхәббәт,сөю хисен,
Алам аннан мәңге сүнмәс яшәү көчен.

1 а.б.:Без бүген үзебезнең туган ягыбыз Актаныш төбәге һәм Чуракай авылы турында сөйләшербез.
2 а.б.:Иң элек,нинди як соң ул- Актаныш ?
1а.б.:Ул- Республиканың көнчыгышында урнашкан.Кышның-иң салкын, җәйнең-иң коры яки иң яңгырлы көннәре кайда?-дисәгез,ул-Актаныштa. Район 1930 елның 20 августында төзелә, үзәге-Актаныш авылы. Аның территориясендә 88 авыл бар. Биредә 33869 кеше яши, шуның 98,07% татарлар,1,83% марилар,калган өлешен руслар,башкортлар, һәм башка халык вәкилләре тәшкил итә.
Җирләре дулкынлы тигезлеккә урнашкан.Ком,ташлы ком,торф ятмалары бар.Соңгы елларда алтын барлыгы беленде, нефть чыгарыла.
1а.б.:Актаныш турында берсеннән-берсе матур риваятьләр дә сөйләнелә. Әйдәгез, аларны тыңлап китик.
1 укучы: Авыл аша аккан елгада су тегермәне булып,шактый тирән генә буасы да була. Менә шул буада,су коенган вакытта "Актаныш" кушаматлы малай суга батып үлә. Елгага Актаныш исеме кушыла. Озакламый авыл да Актаныш дип атала башлый.
2 укучы: Авыл аша кечкенә генә инеш агуы, аның суының саф, чиста булуы,хәтта төбендәге ташлар күренеп торуы әйтелә. Кешеләр бу инешкә сокланып: "Ак инеш", "Акты инеш",-дия торган булганнар. Шуннан инеш Актанышка әйләнеп, авыл да шулай әйтелә башлаган.
3 укчы: Имеш, бер гаиләгә ерактан танышлары кунакка килә. Аны капка төбендә хуҗаның малае каршы ала. Килгән кеше каладан булып, ак йөзле була.Малай

әтисе янына барып, аны ак танышы чакыруын әйтә. Әтисе янындагылар көлешәләр һәм малайга “Актаныш” дигән  кушамат беркеп кала.
2 а.б.Актанышыбызның гербына күз салыйк әле.Ул нәрсә турында сөйли икән?
(1 укучы герб турында аңлата)
1 а.б. Кеше гомере-диңгездзге бер тамчы, мәңгелекнең бер мизгеле генә. Шушы кыска вакыт эчендә кеше зур-зур планнар кора. Җирдә үзенеең үзен калдырырга омтыла.
2 а.б.Актаныш ягыннан бик күп күренекле шәхесләр чыккан. Әйдәгез, алар белән таныштырып үтик..
-М.Ш.Шәймиев-Республикабызның Беренче президенты.
-Шагыйрь һәм язучылар: Н.Баян ,Г.Афзал, Р.Ишморат ,В.Имамов, Л.Лерон, Э.Шарифуллина,Л.Шәех,һ.б.
-Советлар Союзы Геройлары:Б.Дәүләтов,Х.Заманов,С.Фадеев,Г.Һадимөхәмәтов, Г.Минаев (Н,Орлов)
-Җырчыларыбыз:Х.Шәйдуллин,А.Вәлиев,Л.Муллагалиева,Г.Фарукшин, Ә.Авзалова,А.Тимершәех, һ.б.
Җыр тыңлау :Ә.Авзалова “Актаныш таңнары”.

1.а.б.Мин туганмын нинди матур җирдә-
Бабаларым корган  нигездә.
Туган авылым- Чуракай,
Горурланып яшим мин синдә.

2.а.б.Туган якның һавасы да
Җанга рәхәтлек бирә
Сандугачлары сайраса,
Авылыма ямь бирә.

1 а.б.Зурмы, кечкенәме- һәр кешегә үзенең туган төбәге, аның табигате,кешеләре якын була.
2 а.б.Үзебез туып үскән, беренче тапкыр аяк атлап киткән җирне мин туган җир дим.
1 а.б. Әйе, туган як ул- туган йортыбыз,бәрәңге бакчабыз,чишмәбез, кадерле эти-әниебез, туган авылыбыз,районыбыз, республикабыз.
(“Туган авылым” сочинение тыңлап китү)
“Чуракай” җыр башкару
2 а.б. Ни өчен авылның атамасы Чуракай дип йөртелгәнен әле күпләр белмидәдер.
1а.б. Чыннан да, ни өчен шулай атала Актаныш районындагы бу авыл?
“Чуракайга нигез салучылар”(Шаехов А. сөйли)
“Кадергол нәселе шәҗәрәсе” (Галләмов А. сөйли)
“Батыршиннар-безнең авыл тарихында тирән эз калдырган шәхесләрнең берсе”. сөйли Шабаева Р.
-Ә хәзер сүзне  бүген безгә кунак булып килгән, авылыбыз тарихын язучы Кадергулов Фарсил Мостафа улына бирәбез.
Укытучы:Кеше кайда гына йөрсә дә, кайда гына яшәсә дә, аның уенда,йөрәгендә һәрчак кендек каны тамган газиз туган җире була. Туган илем- туган анам дип тиккә генә әйтмиләр бит  Әти-әниләрегезгә, бер-берегезгә, туган җирегезгә

игелекләр генә кылып яшәгез. Авылыбызның, илебезнең киләчәге сезнең кулда,укучылар!